# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында" 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендәге "әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**"1 статья**

Әлеге Закон "Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләүне билгеләү турында" 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгели.";

3) 2 статьяда:

а) 1 өлештә "ваклап сату предприятиеләренә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен" сүзләрен "алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларга, сыра һәм сыра эчемлекләрен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарларга (алга таба – оешмалар, индивидуаль эшкуарлар) алкоголь продукциясен" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә "әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган" сүзләрен төшереп калдырырга, "оешманың" сүзеннән соң ", индивидуаль эшкуарның" сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә "Алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы ваклап сату предприятиеләре" сүзләрен "Оешмалар, индивидуаль эшкуарлар" сүзләренә алмаштырырга, "әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган" сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында" 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) 2 статьясындагы 1 өлешендә каралган таләп сырага һәм әзер продукция күләменең 5 проценты һәм аннан да кимрәге этил спирты булган сыра нигезендә әзерләнүче эчемлекләргә карата кулланылмый.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 69-ТРЗ